РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» апрель, 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 158

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2018 елның 24нче гыйнварындагы 109нчы номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе Кодексын яңа редакциядә раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2007нче елның 2нче мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт» Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2018 елның 24нче гыйнварындагы 109нчы номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе Кодексын яңа редакциядә раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 4пунктны төшереп калдырырга.

Кушымтада 3.10. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.10. «Җирле администрация белән җитәкчелек итүче муниципаль берәмлек башлыгы белән якын туганлык (әти-әни, тормыш иптәше, балалары, бертуганнары, шулай ук тормыш иптәшенең бертуганнары, әти-әнисе, тормыш иптәшенең балалары, балаларының тормыш иптәшләре) булган очракта, әгәр муниципаль хезмәт итү бу вазыйфаи затка яки муниципаль хезмәткәргә турыдан-туры буйсынса, яки берсе икенчесенә муниципаль хезмәт иткәндә буйсынса, аларның берсе муниципаль хезмәттән эштән китү юлы яки муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчү юлы белән баш тартырга тиеш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион сайтында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка таратылганнан соң ) көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты Р.Г.Айзатуллова йөкләргә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин